**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ КАРАМЫШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

Улица Школьная, дом 5, село Карамышево, 423119

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**КАРМЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ**

Мәктәп урамы, 5 йорт, Кармыш авылы, 423119

тел./факс 8439642223 email: Karam.Cmn2@tatar.ru

# РЕШЕНИЕ КАРАР

**№ 163** **31 март 2025 ел**

## Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Кармыш авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 25, 26 статьялары, «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Кармыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 38 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Кармыш авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Кармыш авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун елга расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын, аның график сурәтен дә кертеп, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгару юлы белән (pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (Cheremshan.tatarstan.ru), түбәндәге адреслар буенча урнашкан Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Кармыш авыл җирлегенең Кармыш, Яшәүче торак пунктлары территорияләрендәге махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә:

Кармыш авылы, Бари Габдрахманов ур., 44А йорты (Авыл мәдәният йорты бинасы);

Яшәүче авылы, Совет ур., 26Б йорты (Авыл клубы бинасы).

3. Карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

**Кармыш авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе** **Р.Р.Гатина**

Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Кармыш авыл җирлеге
Советының 2025 елның
31 мартындагы 163 номерлы карарына
1 нче кушымта

**1 нче Кармыш бермандатлы сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 40

Округка Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Кармыш авыл җирлеге урамының бер өлеше керә: Карамыш авылы (Мәктәп урамы буенча 1-25 нче йортлар, Мәктәп урамы буенча 26-27 нче йортлардан тыш).

**2 нче Кармыш бермандатлы сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 37

Округка Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Кармыш авыл җирлеге урамының бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Кармыш авылы (Мәктәп урамындагы 26-27 нче йортлар, Бари Габдрахманов урамындагы 1-26 нчы йортлар, Бари Габдрахманов урамындагы 27-96 нчы йортлардан тыш)

**3 нче Кармыш бермандатлы сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 40

Округка Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Кармыш авыл җирлеге урамының бер өлеше керә: Кармыш авылы (Бари Габдрахманов урамындагы 27-45 нче йортлар, Бари Габдрахманов урамындагы 46-96 нчы йортлардан тыш)

**4 нче Кармыш бермандатлы сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 42

Округка Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Кармыш авыл җирлеге урамының бер өлеше керә: Кармыш авылы (Бари Габдрахманов

урамындагы 46-70 нче йортлар, Бари Габдрахманов урамындагы 71-96 нчы йортлардан тыш)

**5 нче Кармыш бермандатлы сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 43

Округка Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Кармыш авыл җирлеге урамының бер өлеше керә: Кармыш авылы (Бари Габдрахманов урамындагы 71-99 йортлар)

**6 нчы Кармыш бермандатлы сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 37

Округка Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Кармыш авыл җирлеге территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Яшәүче авылы (Совет урамы буенча 1-22 нче йортлар, Совет урамы буенча калган йортларны исәпкә алмаганда).

**7 нче Кармыш бермандатлы сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 38

Округка Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Кармыш авыл җирлеге территориясенең бер өлеше керә: Яшәүчы авылы (Совет урамындагы 23-44 нче йортлар) чикләрендә.